Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

«03» март 2022 ел                                                                                    № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 3 мартында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында элегрәк расланган 2021 елның 22 ноябрендәге 1нче номерлы карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнар Җыенының 2021 елның 22 ноябрендәге 2нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

Бикүле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 2100 сум күләмендә кертелгән үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелүче эшләр исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Бикүле авылы торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунттан юл күтәрү, вак таш белән сибү);

күперне ремонтлау;

- Бикүле авылы су башнясына диспетчерлык пункты урнаштыру;

- Бикүле авылында парк зонасын төзекләндерү;

- Бикүле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту мәсьәләсе буенча беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 400 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 216 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенының 201 катнашучысы тавыш бирде;

"ЮК" позициясе өчен җыенның 15 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында элегрәк расланган 2021 елның 22 ноябрендәге 1нче номерлы карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнар Җыенының 2021 елның 22 ноябрендәге 2нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме?:

Бикүле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 2100 сум күләмендә кертелгән үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар

белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелүче эшләр исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Бикүле авылы торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунттан юл күтәрү, вак таш белән сибү);

күперне ремонтлау;

- Бикүле авылы су башнясына диспетчерлык пункты урнаштыру;

- Бикүле авылында парк зонасын төзекләндерү;

- Бикүле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту мәсьәләсе буенча кабул ителгән таныргa.

3. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең әлеге карарын җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р.Х.Садыков

Бикүле авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Х.Садыков